ГЛАВА
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

27.04.2023 п.г.т. Алексеевское № 4-р

**1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына әзерлек һәм бәйрәм итүгә багышланган чаралар үткәрү турында**

Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 8 маендагы ПУ-360 номерлы Указы, «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законын үтәү һәм районның җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләре, предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары эшчәнлеген координацияләү максатларында:

1. 2023 елда 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган чаралар уздырырга.

2. Расларга:

- Алексеевск муниципаль районында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты турында нигезләмәне (1 нче кушымта);

- Алексеевск муниципаль районында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составы (2 нче кушымта);

-Алексеевск муниципаль районында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрү буенча чаралар планы (3 нче кушымта).

3. Алексеевск районы предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре, иҗтимагый берләшмәләре җитәкчеләренә, авыл җирлекләре башлыкларына һәм хәрби комиссариатка тәкъдим итәргә:

-1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм үткәрүдә актив катнашырга;

- Бөек Ватан сугышы ветераннарының, тыл хезмәтчәннәренең социаль хәлен яхшырту һәм аларга өстәмә ярдәм күрсәтү, шул исәптән көнкүреш шартларын яхшырту буенча чаралар күрергә;

- Алексеевск муниципаль районы территориясендә урнашкан хәрби каберлекләрне, мемориалларны һәм һәйкәлләрне тәртипкә китерү эшен оештырырга.

4. «Заря» (Таң) газетасының баш мөхәррире Е.Д. Ахманаевага 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе М.Р. Гайсинга йөкләргә.

**Алексеевск муниципаль**
**районы Башлыгы** **С.А. Демидов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башлыгының 27.04.2023 ел,№ 4-р
боерыгына 1 нче кушымта

**Нигезләмә**

**Алексеевск муниципаль районында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты турында**

1. Алексеевск муниципаль районында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм үткәрү буенча оештыру комитеты (алга таба-оештыру комитеты) Алексеевск муниципаль районында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган тантаналы чараларны әзерләү һәм үткәрү максатларында оештырыла.

2. Оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм боерыклары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә эш итә.

3. Оештыру комитеты турындагы Нигезләмә һәм аның составы Алексеевск муниципаль районы башлыгы боерыгы белән раслана.

4. Оештыру комитетының төп бурычлары булып тора:

1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм үткәрү буенча чаралар Планына (алга таба-чаралар планы)тәкъдимнәр эшләү;

чаралар Планын үтәүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмаларның эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү;

чаралар Планын үтәү мәсьәләләрен карау һәм аны төзәтү буенча тәкъдимнәр эшләү.

5. Оештыру комитеты алдында торган бурычларны тормышка ашыру максатыннан хокуклы:

Оештыру комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнарыннан, җәмәгать берләшмәләреннән һәм оешмаларыннан, предприятиеләреннән һәм учреждениеләреннән билгеләнгән тәртиптә мәгълүмати материаллар сорарга һәм алырга;

Оештыру комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә вакытлыча эшче төркемнәр булдыру;

үз утырышларына җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар җитәкчеләрен, район предприятиеләре, учреждениеләре җитәкчеләрен чакырырга.

6. Оештыру комитеты составына Оештыру комитеты рәисе, Оештыру комитеты рәисе урынбасары һәм Оештыру комитеты әгъзалары керә, алар аның эшендә иҗтимагый нигездә катнашалар.

Оештыру комитеты рәисе булып Алексеевск муниципаль районы Башлыгы тора

7. Оештыру комитеты утырышлары кирәк булганда үткәрелә.

Оештыру комитеты утырышларын Оештыру комитеты рәисе яки аның кушуы буенча Оештыру комитеты рәисе урынбасары алып бара.

8. Утырышларның көн тәртибен, аларны үткәрү урынын һәм тәртибен Оештыру комитеты рәисе билгели.

9. Оештыру комитеты утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

Сорауларны карау нәтиҗәләре буенча Оештыру комитеты утырышында карарлар кабул ителә, алар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Оештыру комитеты карарлары Оештыру комитеты әгъзаларының күпчелек тавышлары белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда Оештыру комитеты утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Оештыру комитеты әгъзасы утырышта булмаган очракта, ул каралган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә әйтергә хокуклы, ул Оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә кушылырга тиеш.

Оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә рәислек итүче кул куя.

10. Оештыру комитеты кабул иткән карарлар районның кызыксынган җирле үзидарә органнарына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларына, предприятиеләренә һәм учреждениеләренә җиткерелә

11. Оештыру комитеты эшчәнлеген матди-техник, документация һәм мәгълүмати тәэмин итүне Алексеевск район Советының оештыру бүлеге башкара.

**Советның Аппарат җитәкчесе** **А.Г. Соловьев**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башлыгының 27.04.2023 ел,№ 4-р
боерыгына 2 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составы**

**Рәис -** С.А.Демидов,Алексеевск мунципаль районы Башлыгы

**Рәис урынбасары -** М.Р.Гайсин, Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

**Әгъзалар:**

| | |
|---|---|
| Е.А.Хәмзина | Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| Р.С.Язынин | Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары |
| Н.А.Фомина | Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы |
| И.К.Свистунов | Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килештерү буенча) |
| М.А.Солдатова | Алексеевск районында ХМ һәм СЯМ ның социаль яклау бүлеге башлыгы (килештерү буенча) |
| А.М.Свистунова | Алексеевск муниципаль районы мәдәният бүлеге башлыгы |
| В.Ю.Рыдаев | “Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге” МКУ җитәкчесе |
| Р.Р.Кабиров | Алексеевск муниципаль районы "Спорт мәктәбе" МБУ директоры |
| В.В.Макаров | Алексеевск муниципаль районының хәрби комиссары (килештерү буенча) |
| О.Г.Кладова | “Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының В.И.Абрамов исемендәге туган як музее” МБУ директоры |
| Е.С.Макарихина | Алексеевск муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы рәисе |
| В.А.Осянин | Хәрби-тарихи клуб һәм “Йолдыз” эзләү отряды җитәкчесе |
| Е.Д.Ахманаева | “Заря” (“Таң”) газетасының баш мөхәррире (килештерү буенча) |

**Советның Аппарат җитәкчесе** **А.Г. Соловьев**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башлыгының 27.04.2023 ел,№ 4-р
боерыгына 3 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрү буенча чаралар планы**

| т/б | Чара исеме | Башкаручылар | Башкару вакыты |
|---|---|---|---|
| **I. Оештыру чаралары** | | | |
| 1 | Территорияләрне төзекләндерү, районның торак пунктларын бәйрәмчә бизәү, урамнарда 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгы символикасын урнаштыру | АМР БК<br>АҖ БК | апрель-май |
| 2 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветераннары мәгълүмат базасын актуальләштерү | СЯБ<br>АҖ БК | ел саен |
| 3 | «Хәтер Вахтасы» республика акциясендә катнашу, Волгоград өлкәсенә эзләү экспедициясенә чыгу | ЯЭСТБ | апрель-май |
| 4 | Республика эзләү отрядлары фестивалендә катнашу | ЯЭСТБ | сентябрь |
| 5 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган Татарстан Республикасы хәрби-патриотик клубларының (берләшмәләренең) республика слетында катнашу | ЯЭСТБ | октябрь |
| 6 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган тантаналы чаралар оештыру һәм үткәрү | МБ<br>МБ<br>ЯЭСТБ<br>ААК | ел дәвамында |

| т/б | Чара исеме | Башкаручылар | Башкару вакыты |
|---|---|---|---|
| 7 | Бөек Ватан сугышы ветераннарына Татарстан Республикасы Рәисе, район Башлыгы исеменнән бүләк азык-төлек җыелмалары һәм котлау открыткалары тапшыру | АМР БК<br>АҖ БК | май |
| 8 | Район предприятиеләре һәм учреждениеләре тарафыннан Мәңгелек утка хәрби дан гирляндаларын һәм венокларын салу тантанасы | Предприятие һәм учреждение җитәкчеләре | 9 май |
| 9 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветераннары белән тантаналы кичәләр һәм очрашулар үткәрү | АҖ БК<br>МБ | ел буе |
| 10 | «Хәтер бакчасы» табигатьне саклау акциясен үткәрү | ЯЭСТБ | апрель-май |
| 11 | Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган күргәзмә оештыру | МБ | апрель-май |
| 12 | Туган як музее фондларын Бөек Ватан сугышы темасына яңа предметлар белән тулыландыру | МБ | ел буе |
| | **II. 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашкан инвалидларнын, шулай ук аларга тиңләштерелгән кешеләрнең социаль-икътисади тормыш шартларын яхшырту буенча чаралар** | | |
| 1 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы инвалидларын һәм ветераннарын һәм аларга тиңләштерелгән гражданнар категорияләрен, шул исәптән Алексеевск үзәк район хастаханәсенең мобиль табиб бригадалары катнашында тирәнтен медицина тикшерүләре үткәрү | «Алексеевск үзәк район хастаханәсе»<br>ДАССО | ел буе |
| 2 | Бөек Ватан сугышы инвалидларын һәм ветераннарын һәм аларга тиңләштерелгән гражданнарны, тыл хезмәтчәннәрен дарулар белән тәэмин итүне оештыру | «Алексеевск үзәк район хастаханәсе»<br>ДАССО | ел буе |
| 3 | Алексеевск муниципаль районы территориясендә бәйрәм чараларында катнашучыларны һәм кунакларны медицина белән тәэмин итүне оештыру | «Алексеевск үзәк район хастаханәсе»<br>ДАССО | 9 май |

| т/б | Чара исеме | Башкаручылар | Башкару вакыты |
|---|---|---|---|
| 4 | Алексеевск аграр көллияте укучылары һәм белем бирү оешмалары тарафыннан 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашучыларның мемориаль урыннарын һәм каберләрен тәртипкә китерү буенча хезмәт десанты оештыру | МБ<br>ЯЭСТБ<br>ААК | апрель-май |
| 5 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар өчен яшәү шартларын яхшырту, өлкәннәр өчен социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә, интернат-йортларда яшәүче сугыш хәрәкәтләре ветераннары, торак биналарның уңайлылыгын арттыру юлы белән | АМР БК<br>СЯБ | ел буе |
| 6 | «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветераннарын торак белән тәэмин итү турында»Россия Федерациясе Президентының 2008 елның 7 маендагы 714 номерлы Указы нигезендә торак белән тәэмин итү өчен нигезләре булмаган 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм ветераннары яшәгән торак биналарны ремонтлау | АМР БК<br>СЯБ | ел буе |
| 7 | Волонтерларны, яшьләр оешмаларын, иҗтимагый оешмаларны җәлеп итеп, 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветераннарына социаль хезмәтләр күрсәтү һәм социаль ярдәм күрсәтү | СЯБ<br>МБ<br>ЯЭСТБ<br>ААК | ел буе |
| 8 | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы карамагындагы учреждениеләр юнәлеше буенча балигъ булмаган гражданнарның 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветераннарына, һәлак булган сугышчыларның гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтү эшендә катнашуы | СЯБ<br>МБ<br>ЯЭСТБ<br>ААК | ел буе |
| | **III. Истәлекле-мемориаль чаралар** | | |

| т/б | Чара исеме | Башкаручылар | Башкару вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | Хезмәт коллективлары йөрешен оештыру һәм үткәрү | АМР БК<br>АЖ БК<br>Предприятие и учрежденияләр | 9 май |
| 2 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашучыларга, тыл хезмәтчәннәренә һәм локаль сугышларда һәм аларга якын территориядә катнашучыларга һәйкәлләрне төзекләндерү буенча эшләрне гамәлгә ашыру | АМР БК<br>АЖ БК | апрель – май |
| 3 | Хәрби каберлекләрне һәм мемориаль комплексларны тәртипкә китерү. 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә багышланган һәйкәлләргә һәм мемориалларга тоташкан мәйданнарны, скверларны, паркларны төзекләндерү буенча эшләрне гамәлгә ашыру | АМР БК<br>АЖ БК | ел буе |
| 4 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы вакыйгаларына, Советлар Союзы Геройларына һәм Россия Федерациясе Геройларына – Татарстан Республикасында туган геройларга багышланган истәлекле-мемориаль корылмаларның торышына мониторинг оештыру | МБ | ел буе |
| 5 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорына караган мемориаль корылмаларда ремонт-тергезелеш эшләре үткәрү (Советлар Союзы Геройлары һәм Дан орденының тулы кавалерлары һәйкәлләрен, мемориаль такталарын һәм бюстларын, обелискларны, стелаларны, мәңгелек утларны, истәлекле ташларны, мемориалларны, мемориаль комплексларны һ. б. торгызу), шул исәптән район территориясендә хәрби каберлекләрне тәртипкә китерү, шулай ук 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы геройлары хөрмәтенә аталган урамнарны һәм мәйданнарны төзекләндерү | АМР БК<br>АЖ БК | ел буе |

| т/б | Чара исеме | Башкаручылар | Башкару вакыты |
|---|---|---|---|
| 6 | Фашист концлагерьлары тоткыннарын азат итүнең 78 еллыгына (1945 елның 11 апреле)багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү | МБ | апрель |
| 7 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы сугышлары урыннарында Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган солдатларның калдыкларын эзләү һәм күмү буенча эзләү экспедицияләрен оештыру һәм үткәрү | Туган як музее | ел буе |
| 8 | «Война в стихах»проектын тормышка ашыру | МБ | апрель-май |
| 9 | Казан, Яр Чаллы, Әлмәт, Әлки, Спас һәм Чистай районнарының хәрби-тарихи клублары катнашында хәрби-тарихи реконструкция | ЯЭСТБ | Июнь, октябрь 2023 ел |
| 10 | Татарстан Республикасы районнары буенча «Хәтер Маршы» еллык яшьләр походын уздыру | ЯЭСТБ | май – июнь |
| | **IV. Мәгълүмати-пропаганда, мәдәни-массакүләм һәм спорт чаралары** | | |
| 1 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган тематик китап күргәзмәләрен оештыру һәм үткәрү | ҮКС | ел буе |
| 2 | Бөек Ватан сугышы башлануга 80 ел тулуга багышланган ирекле акция кысаларында «Россиянең бөек сугышларының гаилә фотохроникалары»Бөтенроссия конкурсында катнашу | МБ<br>Ветеранар җәмгыяте<br>ЯЭСТБ<br>ААК | январь-июнь |
| 3 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветераннарын чакырып, патриотик темага спектакльләр күрсәтү | МБ | май |
| 4 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы фронтларында якташларыбызның батырлыклары турында хәрби-патриотик тематикалы фильмнар һәм Татарстан Республикасы кинематографистлары төшергән фильмнарның тематик кино күрсәтүләрен оештыру һәм үткәрү | МБ | май |

| т/б | Чара исеме | Башкаручылар | Башкару вакыты |
|---|---|---|---|
| 5 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган әдәби-патриотик әңгәмәләр-презентацияләр, хәтер сәгатьләре үткәрү. 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү көненә китап-иллюстратив күргәзмәләр оештыру | МБ | ел буе |
| 6 | «Аллея памяти», «Георгиевская ленточка», «Свеча памяти», «Голубь мира», «Флаги России», «Окна Победы», «Красная гвоздика» акцияләрен үткәрү | МБ<br>МБ<br>СЯБ<br>ЯЭСТБ | апрель-май |
| 7 | Музей педагогикасы программасы нигезендә мәктәп укучылары белән тематик экскурсияләр һәм дәресләр үткәрү | МБ | апрель-май |
| 8 | Туган як музеенда барлык категория гражданнар өчен Ачык ишекләр көне | МБ | 9 май |
| 9 | Укучыларның уку конкурсын үткәрү«О том, что было, не забудем…» | БСМ | апрель-май |
| 10 | Социаль челтәрләрдә промо-акция үткәрү«И помнит мир спасенный» | БСМ | май |
| 11 | Педагогларның һәм укучыларның муниципаль, республика, бөтенроссия дәрәҗәсендәге конкурсларда, фәнни-гамәли конференцияләрдә, семинарларда катнашуы:<br>- «Растим патриотов России»;<br>- «Любознательные исследователи окружающего мира»;<br>- «Служу Отечеству!»;<br>- «Тайны родного края»;<br>-«Наша Победа»;<br>-«Родные лица Победы»; | МБ | ел буе |
| 12 | Мәгариф оешмалары укучылары арасында Акция «Письмо солдату» | МБ | февраль |

| т/б | Чара исеме | Башкаручылар | Башкару вакыты |
|---|---|---|---|
| 13 | Мәгариф оешмалары укучылары арасында патриотик җыр Фестиваль-конкурсы «Песни в солдатской шинели» | МБ | март-май |
| 14 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветераннарын чакырып спорт чаралары үткәрү | ЯЭСТБ | май |
| 15 | Мәгариф оешмаларында «Ветеран, мы рядом!» и «Сохраним память поколений», «Возьми себе в пример героя» ирекле (волонтерлык), тимурчылык хәрәкәтләре вәкилләрен җәлеп итеп акцияләр үткәрү | МБ<br>СЯБ | ел буе |
| 16 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган йөзү буенча ярышлар, Алексеевск муниципаль районы предприятиеләре һәм оешмалары арасында XV Спартакиада кысаларында Юрий Алексеевич Гагарин Кубогына | ЯЭСТБ | апрель |
| 17 | Алексеевск муниципаль районының шахмат буенча турниры, 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган, Э. Х. Миндубаев истәлегенә | ЯЭСТБ | апрель |
| 18 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган йөзү буенча ярышлар. | ЯЭСТБ | апрель |
| 19 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына, СССР Герое Н.В. Мамонов истәлегенә багышланган ирекле көрәш буенча республика турниры | ЯЭСТБ | май |
| 20 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган 2009-2010 елгы егетләр арасында волейбол буенча турнир. | ЯЭСТБ | май |
| 21 | 2005 елда туган һәм аннан яшьрәк егетләр һәм кызлар арасында өстәл теннисы буенча турнир, 1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган. | ЯЭСТБ | май |

| т/б | Чара исеме | Башкаручылар | Башкару вакыты |
| --- | --- | --- | --- |
| 22 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган 2011-2012 елгы кызлар арасында волейбол буенча турнир. | ЯЭСТБ | май |
| 23 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган Марафон | ЯЭСТБ | май |
| 24 | Алексеевск районы предприятиеләре һәм оешмалары арасында XV Спартакиада кысаларында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган җиңел атлетика эстафетасы. | ЯЭСТБ | май |
| 25 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган 2012-2013 елгы егетләр арасында мини-футбол буенча турнир. | ЯЭСТБ | май |
| 26 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган 2014 елгы һәм кечерәк яшьтәгеләр арасында мини-футбол буенча турнир. | ЯЭСТБ | май |
| 27 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган билбау көрәше буенча республика турнирында катнашу. | ЯЭСТБ | май |
| 28 | 1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган,2013-2014 елларда туган егетләр арасында баскетбол буенча Алексеевск муниципаль районы беренчелеге. | ЯЭСТБ | май |
| 29 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган 2011 елгы кызлар арасында баскетбол буенча Алексеевск муниципаль районы беренчелеге | ЯЭСТБ | май |
| 30 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүне бәйрәм итү чараларын «Заря» район газетасында, район сайтында ятырту | «Заря» район газетасы | май |